ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕШАНДЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление                                                                 Карар

№ 18                                                                 «14 декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2017елның 22 декабрендәге
№7 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карарлары нигезендә, Түбән Шүләңгер авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы тотрыклылыкны арттыру максатларында Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә чүп, үләннәр, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017елның 22 декабрендәге №7карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Караның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан шәхси йортлар территорияләрендә ризык әзерләү өчен махсус бүленгән һәм моның өчен җиһазландырылган урыннардан тыш ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела.»

1.2. Караның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

| N п/п | Торак пункт исеме | Чүп яндыру урыны | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Җөри авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |
| 2. | Түбән Шүләңгер авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 3. | Урта Шүләңгер авылы | Торак пунктның көньяк өлешендә | Башкарма комитет |
| 4. | Ылыя авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |
| 5. | Комаровка авылы | Торак пункттан көнчыгыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 6. | Каенлык Аланы авылы | Торак пунктның көньяк өлешендә | Башкарма комитет |

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:
«Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру ысулы - ачык учак дип билгеләргә.»

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:
«Чүп –чарны яндыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә башкарырга.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында , Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Шүләңгер
авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе /Е.М.Михайлова/